# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге Баек авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

25.11.2021 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1. 56 нчы матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче матдәсе нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2021нче елның 25нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2022 нче елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Баек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә; Бөек Ватан Сугышы ветераннарына, I-II төркем инвалидларга, Әфганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 1000 (бер мең) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.
- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.
- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.
-Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.
-Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.
-Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.
-Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.
-Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.
-Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

«РИЗА» - 120 «КАРШЫ»- 7

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 245 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 127, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 120 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 7 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Баек авыл җирлегенең Дусай авылы торак пунктында гражданнар җыены узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 нче елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Баек авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә; Бөек Ватан Сугышы ветераннарына, I-II төркем инвалидларга, Әфганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.

- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.

- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

- Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.

- Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.

- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.

- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.

- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Баек авыл җирлеге башлыгы** **М.Ф. Фахерлегаянов**